**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында граждан оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Граждан оборонасы өлкәсендә федераль законнарга үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 17 октябрендәге ПУ-995 номерлы, 2016 елның 19 гыйнварындагы ПУ-18 номерлы, 2016 елның 4 июнендәге ПУ-502 номерлы, 2020 елның 27 гыйнварындагы ПУ-27 номерлы, 2022 елның 23 апрелендәге ПУ-297 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 24 мартындагы 187 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында граждан оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәнең 3.2 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«халыкка хәбәр итү системаларын, шул исәптән халыкка хәбәр итүнең муниципаль һәм локаль системаларын төзү, яңартып кору һәм файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту;»;

б) өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге Указ 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2024 ел, 26 июль
№ 563